**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 16 декабрендәге 5167 номерлы карары**

## Казан шәһәре Авиатөзелеш районындагы Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проектын раслау турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Кадастр Недвижимости» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45 һәм 46 статьяларына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 4727 номерлы карары белән расланган Дементьев һәм Академик Павлов урамнары киселешендә территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 13 июлендәге 1916 номерлы «Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы, 2020 елның 18 декабрендәге 3771 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 13 июлендәге 1916 номерлы “Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проектын әзерләү турында”гы карарына үзгәреләр кертү хакында»гы карараларын Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыруны һәм 2020 елның 13 июлендә һәм 2020 елның 31 декабрендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең

документлары һәм хокукый актлары җыентыгында бастырып чыгаруны күз уңында тотып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проектын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга;

1.2. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, транзит коммуникацияләрнең планлаштырыла торган сервитутлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләреннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга;

1.3. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләреннән, транзит коммуникацияләрнең планлаштырыла торган сервитутлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.4. әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына (Р.Г.Галәветдинов) әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән 600 кв.м мәйданлы җир кишәрлегенә дәүләт кадастр исәбе үткәргәннән соң, Ягодин Максим Роберт улы белән 2019 елның 20 декабрендәге 20549 номерлы аренда килешүенә үзгәрешләр кертү турында килешү яисә барлыкка килә торган җир кишәрлеген, сатулар (конкурслар, аукционнар) уздырмыйча, элеккеге шартларда арендалау килешүен төзеп, 2019 елның 20 декабрендәге 20549 номерлы аренда килешүен өзү турында килешү төзергә.

2. «Кэпитал Риэлт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, гражданнар: Гасымов Назим Гусейн оглына, Гасымов Асиф Гусейн оглына**,** Ягодин Максим Роберт улына **тәкъдим** итәм:

2.1. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү өчен әлеге карар кушымтасы нигезендә тиешле документларны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына тапшырырга;

2.3. Әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр исәбен алып барганнан соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә адреслы номерлар бирү һәм Дәүләт адреслы реестрына белешмәләр кертү өчен җир кишәрлекләренең кадастр номерлары турында мәгълүмат тапшырырга;

2.4. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

2.4.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмалар өчен аларга тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;

2.4.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 декабрендәге
5167 номерлы карары белән
расланган

**Казан шәһәре Авиатөзелеш районындагы**
**Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проекты**

Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрне үз эченә ала:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линия чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, транзит коммуникацияләре буенча планлаштырыла торган ачык сервитутлар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләре белән территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә.

II. Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проектының 1 номерлы һәм 2 номерлы сызымнары.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, транзит коммуникацияләре буенча планлаштырыла торган ачык сервитутлар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләре хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып торалар һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проекты, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 4727 номерлы карары белән расланган Дементьев һәм Академик Павлов урамнары киселешендә территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты чикләрендә эшләнгән.

Дементьев урамы буенча территорияне ызанлау проекты яңа капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырылмаган төзелеш территориясе өчен кызыл линияләрне үзгәртүне күз уңында тота, һәм мондый кызыл линияләр урнаштыру асылда барлыкка килгән чикләр нигезендә гомуми файдалану территориясе чикләрен үзгәртүгә, шулай ук җир кишәрлекләре барлыкка килүгә китерә. Дементьев урамындагы юлның һәм тротуарларның факттагы чикләре өлешендә беркадәр корректировка юлның Дементьев һәм Академик Павлов урамнары киселешендә планлаштыру һәм ызанлау проекты белән расланган аркылы профиленә туры килә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә «ЗУ1» шартлы билгеле барлыкка килә торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре булып кадастр номеры 16:50:220527:683 булган беренчел җир кишәрлегеннән файдалану төрләре – 4.8.1. Күңел ачу чаралары; 3.2.2. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү; 4.7. Кунакханә хезмәте күрсәтү; 3.6.1. Мәдәни-ял итү эшчәнлеге объектлары; 4.3. Базарлар; 4.6. Җәмәгать туклануы; 4.1. Эшлекле идарә; 4.4. Кибетләр; 4.10. Күргәзмә, ярминкә эшчәнлеге; 4.2. Сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре [комплекслар] танылa, «ЗУ2» шартлы билгеле барлыкка килә торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре булып кадастр номеры 16:50:220527:681 булган беренчел җир кишәрлегеннән файдалану төрләре – амбулатор ветеринария хезмәте күрсәтү, кибетләр, җәмәгать туклануы таныла, «ЗУ3» шартлы билгеле барлыкка килә торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре булып кадастр номеры 16:50:220517:1544 булган беренчел җир кишәрлегеннән файдалану төре – сәүдә объектлары (бишенче төр) таныла.

Казан шәһәр Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, барлыкка килә торган җир кишәрлекләре өлешчә урам-юл челтәренең ярдәмче зонасында урнашкан. Ярдәмче зонаның чикләре гомуми файдаланудагы территория чикләре буенча төгәлләштерелергә тиеш. Җир кишәрлекләрен барлыкка китерү урам-юл челтәренең ярдәмче зонасы чикләрен

гомуми файдаланудагы территориянең кызыл линияләр белән билгеләнгән чикләренә китергәндә генә мөмкин.

Территорияне ызанлауны түбәндәгечә үткәрү каралган:

- муниципаль милектәге кадастр номеры 16:50:220527:645 булган җир кишәрлеген, гомуми өлешле шәхси милектәге кадастр номеры 16:50:220527:683 булган җир кишәрлеген дәүләт милке чикләнмәгән җирләр белән җир ашалыкны бетерү өчен яңача бүлү юлы белән 4600 кв.м мәйданлы ЗУ1 җир кишәрлешен ясау, шулай ук гомуми файдаланудагы территориянең фактта барлыкка килгән чикләре нигезендә кызыл линияләр билгеләү;

- шәхси милектәге кадастр номеры 16:50:220527:681 булган җир кишәрлеген дәүләт милке чикләнмәгән җирләр белән җир ашалыкны бетерү өчен яңача бүлү юлы белән 640 кв.м мәйданлы ЗУ2 җир кишәрлеген ясау, шулай ук гомуми файдаланудагы территориянең фактта барлыкка килгән чикләре нигезендә кызыл линияләр билгеләү;


- дәүләт милкендәге кадастр номеры 16:50:220517:1544 булган җир кишәрлеген дәүләт милке чикләнмәгән җирләр белән рөхсәт ителә торган иң чик күләмнәре нигезендә бер-берсенә керүне, җир ашалыкны бетерү өчен яңача бүлү юлы белән 600 кв.м мәйданлы ЗУ3 җир кишәрлеген ясау, шулай ук гомуми файдаланудагы территориянең фактта барлыкка килгән чикләре нигезендә кызыл линияләр билгеләү.

## Ясала торган җир кишәрлекләренең исемлеге

| Кишәрлек номеры | Мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры |
|---|---|---|---|
| ЗУ1 | 4600 | 4.8.1. Күңел ачу чаралары; 3.2.2. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү; 4.7. Кунакханә хезмәте күрсәтү; 3.6.1. Мәдәни-ял итү эшчәнлеге объектлары; 4.3. Базарлар; 4.6. Җәмәгать туклануы; 4.1. Эшлекле идарә; 4.4. Кибетләр; 4.10. Күргәзмә ярминкә эшчәнлеге; 4.2. Сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслар)) | 16:50:220527:645<br>16:50:220527:683 |
| ЗУ2 | 640 | Амбулатор ветеринария хезмәте күрсәтү, кибетләр, җәмәгать туклануы | 16:50:220527:681 |
| ЗУ3 | 600 | Сәүдә объектлары (бишенче төр) | 16:50:220517:1544 |




# II. Дементьев урамы буенча территорияне ызанлауның 1 номерлы сызымы

## Масштаб 1:2000




## Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләренең чикләре |
| | гамәлдәге кызыл линияләр |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| н1 | ясала торган җир кишәрлеге чикләренең, билгеләнә торган кызыл линияләрнең, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| **ЗУ1, ЗУ2, ЗУ3** | ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше |
| | кадастр кварталы чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләре |
| | ызанлау проекты территориясе чикләре |
| | беренчел җир кишәрлегенең билгеләнеше |
| 16:50:220527<br>16:50:220517 | кадастр кварталы билгеләнеше |

| | |
|---|---|
| 16:50:220527:681<br>16:50:220527:683<br>16:50:220527:645<br>16:50:220517:1544 | беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры |
|  | транзит газүткәргечнең планлаштырыла торган сервитуты |
|  | транзит суүткәргечнең планлаштырыла торган сервитуты |
|  | транзит канализациянең планлаштырыла торган сервитуты |
|  | тышкы яктыртуның транзит һава линиясенең планлаштырыла торган сервитуты |
|  | транзит электр кабеленең планлаштырыла торган сервитуты |
|  | транзит җылылык үткәргечнең планлаштырыла торган сервитуты |

## II. Дементьев урамы буенча территорияне ызанлауның 2 номерлы сызымы

## Масштаб 1:2000




## Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләренең чикләре |
| | гамәлдәге кызыл линияләр |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| | беренчел җир кишәрлегенең билгеләнеше |
| **н1** | ясала торган җир кишәрлеге чикләренең, билгеләнә торган кызыл линияләрнең, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| **ЗУ1, ЗУ2, ЗУ3** | ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше |
| | кадастр кварталы чикләре |
| | ясала торган җир кишәрлеге чикләре |
| | ызанлау проекты территориясе чикләре |
| 16:50:220527<br>16:50:220517 | кадастр кварталы билгеләнеше |

| | |
|---|---|
| 16:50:220527:681<br>16:50:220527:683<br>16:50:220527:645<br>16:50:220517:1544 | беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры |